**6 НЧЫ САН**
**АПРЕЛЬ**
**2025**

***Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы***
***«Апаз балалар бакчасы » муниципаль бюджет***
***мәктәпкәчә белем биру учреждениесе***

# ЧИШМӘ БАШЫ

*Бакчабызның бүгенгесен яктыртучы мәгълүмати электрон газетасы*



Газетаның сәхифәләре:

*12 нче апрель – «Космонавтика көне»
* 26- апрель Бөек Тукаебызның туган көне
* Габдулла Тукай безнен кунелләрдә яши
*Май аена сынамышлар

**Баш мөхәррир- тәрбияче: Нигъмәтҗанова Лилия Гаптеләхәт кызы.**
**Мөхәррир урынбасары - бакча мөдире: Зәйнуллина Индира Тәлгать кызы.**





1961 елның 12 апрель көне тарихка кереп калган истәлекле дата. Бу көнне космоска кешелек тарихында беренче тапкыр пилотлы очыш ясалды.Галәмгә беренче тапкыр юл ачкан вакыйганы һәм Юрий Гагаринны искә алмаган кеше юктыр.
1960 елның августында космос кинлекләренә Белка һәм Стрелка исемле этләрнең очышы әһәмияткә ия. Этләр очышны уңышлы башкарып җиргә исән- сау әйләнеп кайталар.
1961 елның 12 апрелендә Юрий Гагарин беренче кеше булып космоска күтәрелә. Ул галәмгә юл ачканнан соң космик ачышлар дәвам иттерелә.
Җир тарихында яңа эра ачкан герой Ю.А.Гагаринның исеме кешелек җәмгыятенең елязмасында алтын хәрефләр белән язылган.
Ю.Гагарин батырлык, хезмәт сөючәнлек, кешенең бетмәс – төкәнмәс мөмкинлекләре символына әйләнде. Юрий Гагарин исеме тарихка кереп калды.










Тукай әдәбиятыбыз кугендә балкыган йолдызларнын ин яктысы. Габдулла Тукай 1886 елнын апрель аенда Арча районы Кушлавыч авылында доньяга килә. Габдуллага 4 ай дигәндә әтисе, 4 яшь тулганда энисе вафат булалар. Шул коннәрдән булачак шагырьнен ачы ятимлек тормышы башлана. Язмыш аны бер гаиләдән икенче гаиләгә,бер урыннан икенче урынга ташлый. Кырлайда аны Сәгьди исемле авыл агае асраугa ала. Габдулла шунда мәдрәсәдә укый башлый. 1985 елда Тукайны Уралски шәхәренә озаталар. Шул ук елны Габдулла “Мотыгия” мәдрәсәсендә укый башлый. Укыган еллар Тукайнын шагыйрь буларак зур роль уйный. Яшь шагырьнен рухи доньясы киңәя. Ул торек, гарәп телләрен тирәнтен өйрәнә.Һәм узе дә иҗатта кочен сынап карый. Беренче сатирик шигырьләрен яза. Ул нибары бер-ике ел эчендә халыкнын яраткан шагыйренә әверелә.

Шүрәле поэмасын Габдулла Тукай 1907 елда яза. Шул ук елны ул Казанга килә һәм гөмеренең соңгы көненә кадәр шунда кала. Г.Тукай бары тик 27 ел гына яши, әмма бик күпне эшләргә өлгерә. Ул үзе исән чагында ук халык шагыйренә эверелә. Алар дөнья халыкларынын күп телләренә тәрҗемә ителә.

Габдулла Тукайны без онытмыйбыз, ул безнең күңелләрдә яши.






ПОБЕДА








# МАЙ АЕ СЫНАМЫШЛАРЫ

1 майда җылы булса, май ахыры салкынча булыр.
2 майда каен яфрак ярса, җәй коры килер.
3 майда ике яки өч катлы салават күпере чыкса, берничә көннән көчле яңгыр булыр.
4 майда шомырт чәчәк атса, җәй җылы килер.
5 майда төнлә салкынайтса, 40 көн буена иртәләр салкын булыр.
6 майда көн суык булып, бер атнада тагын кабатланса, җылы көз көтегез.
7 майдан соң, гадәттә, 12 суык була.
8 майда яңгыр яуса, арыш уңа.
9 майда көндез җил көчле булып, кичкә тынса, тотрыклы аяз көннәргә ишарә.
10 майда кояш чыкканда, көн аяз булса – җәй җилле булыр.
11 майда таң атканда йолдызлар җемелдәшсә, якын арада яңгыр көтелә. Күбәләкләр өйгә яки сарайга кереп качса, көн суыта.
12 майда көчле җил — көчле яңгыр алып килә.
13 майның җылы киче һәм йолдызлы төне – мул уңыш билгесе.
14 майда көн бозыла икән, кыш салкын булыр.
15 май төнендә сандугач төне буе сайрап чыга икән, кояшлы көн көтегез.
16 майда шомырт чәчәк атса – салкынайта, шомырт чәчәге күп булса, яңгырлы җәй килә.
17 майда чыпчыклар төркемләп очса, көчле җил булыр.
18 майда каз суда коенса, көннәр җылыта.
19 майда чык күп төшеп, көн кояшлы булса, кыяр уңышы мулдан булыр.
20 майда кичке салават күпере – аяз, иртәнгесе яңгырлы көнгә. Төнлә су өстенә таман ятып, иртән юкка чыкса, аяз көннәргә ишарә.
21 майда яңгыр яуса, гөмбәле ел килә.
22 майда яңгыр яуса, бодай һәм арыш уңар.
23 майда яңгыр яуса, җәй яңгырлы килер. Тузганак чәчәкләре төштән соң 2дә, 3тә ябылса, яңгыр явар.
24 майда яңгыр сибәләсә, яңгырлы җәй юрыйлар.
25 майда төркем-төркем болытлар бер якка таба гына акса, коры көннәр килә.
26 майда карлыгачлар түбән очса, яңгыр көтегез.
27 майда яр карлыгачлары күренсә, җылы көннәр килә.
28 майда көн кызу булса, җәй дә җылы булыр.
29 майда суда төнбоек яфраклары күрсәгез, язгы суыклар бетте дигән сүз.
30 майда көн нинди булса, җәй дә шундый.
31 майда черкиләр болыт булып җыелса, матур һава торышына. Бал кортлары шомырт һәм миләш чәчәгенә кунса, июньнең беренче көне матур булыр.